**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Кадер авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 97** **«19»апрель 2023 ел**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советының 2020 елның 14 нче августның 213 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы, "Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында" 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы, "Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2023 елның 24 февралендәге 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары һәм "Муниципаль вазыйфага яисә контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфасына дәгъва кылучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе турында" Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советының 2020 елның 14 нче августында 213 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктта икенче абзацта "Татарстан Республикасы Президентын" сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен)» (алга таба – Татарстан Республикасы Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 4 пунктта "Татарстан Республикасы Президентын" сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 5 пунктта икенче абзацта "Татарстан Республикасы Президентын" сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 6 пунктта "Татарстан Республикасы Президентын" сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 7 пунктта "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен тиешле килештә «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 11 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Кадер авыл җирлеге Советы рәисе** **Л.Н.Барсукова**